ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2021 Казан ш. № 519-109/тэ-2021

«ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 №5-92/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм, 2022 елга җайга салынулы оешманың план буенча кирәкле тулай керемен тәгаенләп, 2022 елга «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә дәвамлы тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә

2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 19.12.2018 № 5-92/тэ карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 №5-121/тэ, 16.12.2020 № 455-91/тэ-2020 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә биреп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-92/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2021 № 519-109/тэ-2021 карары редакциясендә)

## «ТГК-16» АЖ тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукциялән гән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см² кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см² кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см² кадәр | 13,0 кг/см² югары | |
| 1 | «ТГК-16» АЖ | | | | | | | |
| 1.1 | Казан шәһәре | | | | | | | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 682,82 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 910,54 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 824,54 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 855,28 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 815,28 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 844,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 809,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 838,38 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 785,05 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 835,56 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге